КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 июль г.Казань № 699

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга «Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2015 ел, 29 апрель, 299 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 671 нче; 2016 ел, 23 июнь, 429 нчы; 2016 ел, 23 сентябрь, 682 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 1000 нче; 2017 ел, 7 февраль, 62 нче; 2017 ел, 15 февраль, 88 нче; 2017 ел, 8 июнь, 362 нче; 2017 ел, 26 июнь, 436 нчы; 2017 ел, 22 декабрь, 1028 нче; 2017 ел, 25 декабрь, 1030 нчы; 2018 ел, 21 май, 383 нче; 2018 ел, 24 сентябрь, 842 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1182 нче; 2019 ел, 8 апрель, 275 нче; 2019 ел, 3 июнь, 464 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 854 нче; 2020 ел, 27 гыйнвар, 24 нче; 2020 ел, 28 май, 437 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1086 нчы; 2021 ел, 30 июль, 666 нчы; 2022 ел, 19 май, 464 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә

алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа исеме | «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Программа)»; |

«Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | Программа 2014 – 2025 елларда гамәлгә ашырыла.<br>Программаны гамәлгә ашыру ярдәмче программаларда һәм чаралар исемлегендә күрсәтелгән чараларны максатчан финанслау принцибы буенча гамәлгә ашырыла»; |

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | «2014 – 2025 елларга тимер юл инфраструктурасын үстерү»;<br><br>«2014 – 2025 елларга эчке су юлларының һәм елга портларының елга транспортын үстерү»;<br>«2014 – 2025 елларга һава транспортын һәм аэронавигацияне үстерү»;<br>«2014 – 2025 елларга автомобиль, шәһәр электр транспортын, шул исәптән метроны үстерү»;<br>«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында логистика үзәкләре челтәрен үстерү»;<br>«2014 – 2025 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклап калу»;<br>«2014 – 2025 елларга транспорт системасы иминлеге дәрәҗәсен арттыру»;<br>«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү»;<br>«2015 – 2025 елларга транспорт тармагында энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру»; |

«Еллар буенча Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>2014 – 2025 елларга Программаны тормышка ашыруга җәлеп итәргә планлаштырыла торган ассигнованиеләр күләме 637 484,034 млн.сум тәшкил итә:<br>(млн.сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барысы</th><th colspan="4">Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы</th></tr>
<tr><th>җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган федераль бюджет</th><th>Татарстан Респуб-ликасы бюджеты</th><th>җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган бюджеттан тыш чыганак-лардан</th><th>җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган муниципаль юл фондлары</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>38 357,508</td><td>10 647,253</td><td>26 788,455</td><td>88,2</td><td>833,6</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>38 437,312</td><td>9 769,212</td><td>27 480,46</td><td>506,94</td><td>680,7</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>43 154,980</td><td>11 540,878</td><td>30 475,688</td><td>353,314</td><td>785,1</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>49 839,651</td><td>11 256,408</td><td>37 283,232</td><td>220,311</td><td>1 079,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>57 971,231</td><td>10 488,906</td><td>46 190,788</td><td>262,837</td><td>1 028,7</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>57 305,198</td><td>14 840,85</td><td>40 879,143</td><td>497,605</td><td>1 087,6</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>62 570,966</td><td>16 865,91</td><td>44 521,723</td><td>60,933</td><td>1 122,4</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>77 076,026</td><td>27 704,111</td><td>48 066,086</td><td>120,129</td><td>1 185,7</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>59 288,625</td><td>25 207,82</td><td>30 789,934</td><td>2 040,671</td><td>1250,2</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>61 897,029</td><td>27 255,83</td><td>31 441,199</td><td>3 200,0</td><td>–</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>62 658,665</td><td>27 638,875</td><td>31 819,79</td><td>3 200,0</td><td>–</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>28 926,843</td><td>440,361</td><td>28 486,482</td><td>–</td><td>–</td></tr>
</table>
<br>Бюджет йөкләмәләре күләмнәре тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә ел саен төгәлләштерелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр</td>
<td>Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>Татарстан Республикасы тулаем төбәк продуктының йөк сыйдырышлылыгы дәрәҗәсен 20 процентка киметергә;<br>норматив таләпләргә туры килә торган төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары өлешен 51,9 процентка кадәр арттырырга;<br>гомуми файдаланудагы юллар челтәренә кадәр каты өслекле юллар булган торак пунктларның чагыштырма авырлыгын 83,5 процентка кадәр арттырырга;<br>шәһәр агломерацияләренең норматив хәлдәге юл челтәре өлешен 85 процентка кадәр арттырырга;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | шәһәр элемтәсенең маршрут челтәрен үстерү дәрәҗәсен 3,0 кадәр арттырырга;<br>шәһәрдән тыш элемтәнең маршрут челтәрен үстерү дәрәҗәсен 2,0 кадәр арттырырга;<br>пычраткыч зарарлы матдәләр ташлау һәм чыгару күләмен 10 процентка киметергә;<br>гомуми файдаланудагы транспорт көтүнең уртача интервалын 8,8 минутка кадәр киметергә»; |

Программаның 1 бүлегендә:

1.4.4 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елга кадәр Татарстан Республикасы территориясендә тимер юл транспортын үстерү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 ноябрендәге б-3363 номерлы боерыгы белән расланган 2035 елга кадәрге чорга фараз белән 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең транспорт стратегиясе кысаларында гамәлгә ашырылачак.»;

1.5 бүлекчәдә:

беренче абзацта «2014 – 2024 еллар чорында» сүзләрен «2014 – 2025 еллар чорында» сүзләренә алмаштырырга;

12 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 нче таблица

Тимер юл транспорты үсешенең төп күрсәткечләре фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пассажирлар йөртү (шәһәр яны маршруты) | млн.кеше | 7,9 | 8,0 | 6,8 | 6,9 | 6,4 | 6,07 | 6,4 | 6,5 | 5,032 | 5,875 | 5,9 | 5,9 | 5,9 | 5,9 |
| Пассажирлар әйләнеше (шәһәр яны элемтәсе) | млн.пасс. км | 297,2 | 318,5 | 276,2 | 291,4 | 270,4 | 250,4 | 264,1 | 266,0 | 197,25 | 239,223 | 240,798 | 240,798 | 240,798 | 240,798 |
| Йөкләр ташу | млн.тонна | 16,3 | 15,7 | 15,2 | 15,2 | 14,8 | 15,2 | 15,88 | 15,1 | 15,75 | 15,18 | 15,2 | 15,2 | 15,2 | 15,2»; |

13 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 нче таблица

Һава транспорты төрләрен үстерүнең төп күрсәткечләрен фаразлау

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пассажирларга хезмәт күрсәтү («Казан», «Бигеш» халыкара аэропортлары, «Бөгелмә» аэропорты) | млн.кеше | 2,4 | 2,2 | 2,34 | 3,26 | 3,96 | 4,37 | 2,64 | 4,12 | 4,84 | 5,13 | 5,43 | 5,7 |
| Йөкләргә хезмәт күрсәтү («Казан», «Бигеш» халыкара аэропортлары, «Бөгелмә» аэропорты) | тонна | 4 123,6 | 3 121,2 | 3 047,2 | 3 643,2 | 4 308,9 | 4 057,8 | 3 422,6 | 5 673,8 | 7 052,5 | 7 757,7 | 8 533,4 | 8 960,1»; |

13 нче таблицадан соң абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елга карата 2025 елда пассажирлар йөртү күләме 2,37 тапкырга артачак.»;
14 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 нче таблица

Эчке су транспорты үсешенең төп күрсәткечләре фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пассажирлар йөртү | млн.кеше | 0,5 | 0,4 | 0,37 | 0,36 | 0,36 | 0,33 | 0,33 | 0,28 | 0,34 | 0,30 | 0,34 | 0,35 | 0,36 | 0,37 |
| Пассажирлар әйләнеше | млн.пасс.км | 15,7 | 13,8 | 12,11 | 12,24 | 10,37 | 7,97 | 8,9 | 7,5 | 9,7 | 9,68 | 10,67 | 10,99 | 11,31 | 11,87»; |

15 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 нче таблица

Гомуми файдаланудагы җир өсте пассажирлар транспорты үсешенең төп күрсәткечләре фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Пассажирларны автобуслар белән йөртү (даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында, маршрут таксомоторларын да кертеп (заказлы автобуслардан башка)) | млн.кеше | 276,4 | 276,6 | 276,8 | 276,7 | 276,9 | 216,3 | 216,2 | 216,2 | 157,6 | 200,2 | 249,1 | 261,5 | 274,6 | 274,6 |
| Автобуслар белән пассажирлар йөртү әйләнеше (даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында, маршрут таксомоторларын да кертеп (заказлы автобуслардан башка)) | млн. пасс.км | 2 098,1 | 2 098,4 | 2 098,6 | 2 098,5 | 2 098,5 | 1 379,2 | 1 379,2 | 1 379,2 | 928,3 | 1 179,0 | 1 466,7 | 1 540,0 | 1 617,0 | 1 617,0 |
| Троллейбуслар белән пассажирлар йөртү | млн.кеше | 23,4 | 26,1 | 26,3 | 25,1 | 26,8 | 27,1 | 27,1 | 27,98 | 20,8 | 21,4 | 25,5 | 26,7 | 28,0 | 28,0 |
| Троллейбуслар белән пассажирлар йөртү әйләнеше | млн. пасс.км | 81,0 | 90,4 | 91,2 | 86,7 | 97,1 | 92,0 | 83,0 | 83,0 | 72,0 | 78,0 | 95,0 | 99,7 | 104,7 | 104,7 |
| Трамвайлар белән пассажирлар йөртү | млн.кеше | 50,8 | 53,7 | 53,3 | 56,5 | 52,6 | 47,86 | 42,0 | 42,6 | 35,1 | 35,7 | 37,9 | 39,8 | 41,8 | 41,8 |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Трамвайлар белән пассажир-лар йөртү әйләнеше | млн. пасс.км | 198,9 | 200,6 | 196,5 | 204,1 | 189,2 | 174,79 | 162,5 | 162,5 | 92,7 | 105,5 | 131,3 | 137,8 | 144,7 | 144,7 |
| Метрополитен белән пассажир-лар йөртү | млн.кеше | 21,4 | 31,3 | 29,8 | 28,7 | 27,2 | 26,25 | 27,17 | 27,2 | 21,4 | 24,2 | 29,2 | 30,7 | 32,3 | 32,3 |
| Метрополитен-да пассажирлар әйләнеше | млн. пасс.км | 145,6 | 212,6 | 202,5 | 195,2 | 216,3 | 178,52 | 184,76 | 184,94 | 156,22 | 176,0 | 213,9 | 224,6 | 235,8 | 235,8»; |

1.5.2 бүлекчәнең икенче абзацында «2014 – 2024 елларда» сүзләрен «2014 – 2025 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның 2 бүлегендәге уникенче абзацында «2014 – 2024» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ

2014 – 2024 елларга Программаны тормышка ашыруга җәлеп итәргә планлаштырыла торган ассигнованиеләр күләме 637 484,034 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җәлеп итәргә планлаштыры-ла торган федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштыры-ла торган бюджеттан тыш чыганаклардан | җәлеп итәргә планлаштырыла торган муниципаль юл фондлары |
| 2014 | 38 357,508 | 10 647,253 | 26 788,455 | 88,2 | 833,6 |
| 2015 | 38 437,312 | 9 769,212 | 27 480,46 | 506,94 | 680,7 |
| 2016 | 43 154,980 | 11 540,878 | 30 475,688 | 353,314 | 785,1 |
| 2017 | 49 839,651 | 11 256,408 | 37 283,232 | 220,311 | 1 079,7 |
| 2018 | 57 971,231 | 10 488,906 | 46 190,788 | 262,837 | 1 028,7 |
| 2019 | 57 305,198 | 14 840,85 | 40 879,143 | 497,605 | 1 087,6 |
| 2020 | 62 570,966 | 16 865,91 | 44 521,723 | 60,933 | 1 122,4 |
| 2021 | 77 076,026 | 27 704,111 | 48 066,086 | 120,129 | 1 185,7 |
| 2022 | 59 288,625 | 25 207,82 | 30 789,934 | 2 040,671 | 1 250,2 |
| 2023 | 61 897,029 | 27 255,83 | 31 441,199 | 3 200,0 | – |
| 2024 | 62 658,665 | 27 638,875 | 31 819,79 | 3 200,0 | – |
| 2025 | 28 926,843 | 440,361 | 28 486,482 | – | – |

Әлеге акча, беренче чиратта, түбәндәге проектларны һәм чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдереләчәк:

транспорт эшчәнлегенең куркынычсызлыгын арттыруны тәэмин итә торган;

гомумдәүләт әһәмиятенә ия өстенлекле социаль бурычларны хәл итүгә ярдәм итә торган;

транспортның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясавын киметә торган.»;

Программага 1 – 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга тимер юл инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2025 елларга тимер юл инфраструктурасын үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа)»; |

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс ресурслары – 9 620,421 млн.сум, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 443,845 млн.сум,<br>бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча – 5 176,576 млн.сум (шул исәптән «Россия тимер юллары» ААҖ акчасы).<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә: |

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | |
|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 416,868 | 416,868 | – |
| 2015 | 388,14 | 380,64 | 7,5 |
| 2016 | 284,79 | 284,79 | – |
| 2017 | 308,7 | 308,7 | – |
| 2018 | 346,54 | 346,54 | – |
| 2019 | 422,467 | 422,467 | – |
| 2020 | 380,64 | 380,64 | – |
| 2021 | 380,64 | 380,64 | – |
| 2022 | 849,716 | 380,64 | 469,076 |
| 2023 | 2 730,64 | 380,64 | 2 350,0 |
| 2024 | 2 730,64 | 380,64 | 2 350,0 |
| 2025 | 380,64 | 380,64 | – |

| | |
|---|---|
| | Чараларны һәм объектларны финанслау күләмнәре төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә тәгаенләштерелергә тиеш»; |

«Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлының беренче абзацында «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортыннан соң унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2025 елларда түбәндәгеләр планлаштырыла:»;

1 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга елга транспортын, эчке су юлларын һәм елга портларын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2025 елларга елга транспортын, эчке су юлларын һәм елга портларын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа): |

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс ресурслары – 1 528,119 млн.сум, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 136,224 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 1 391,895 млн.сум.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә: |

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча |
|---|---|---|---|---|
| 2014 | 153,203 | - | 153,203 | – |
| 2015 | 162,877 | 100,0 | 62,877 | – |
| 2016 | 83,512 | – | 83,512 | – |
| 2017 | 133,742 | – | 133,742 | – |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2018 | 115,792 | – | 115,792 | – |
| 2019 | 179,88 | 36,224 | 143,656 | – |
| 2020 | 120,153 | – | 120,153 | – |
| 2021 | 115,792 | – | 115,792 | – |
| 2022 | 115,792 | – | 115,792 | – |
| 2023 | 115,792 | – | 115,792 | – |
| 2024 | 115,792 | – | 115,792 | – |
| 2025 | 115,792 | – | 115,792 | – |

Чараларны һәм объектларны финанслау күләмнәре төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә тәгаенләштерелергә тиеш»;

«Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 2025 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелергә тиеш:<br>пассажирлар йөртү – 0,37 млн.кеше;<br>пассажирлар әйләнеше – 11,87 млн.пасс.км»; |

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга һава транспортын һәм аэронавигацияне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2025 елларга һава транспортын һәм аэронавигацияне үстерү» (алга таба – ярдәмче программа)»; |

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс ресурслары – 7 610,727 млн.сум, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 1 377,218 млн.сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4 839,799 млн.сум; |

<table>
<tr><td></td><td>бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча – 1 393,71 млн.сум (шул исәптән инвесторлар акчасы).<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә:<br><br>(млн.сум)<br>
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барысы</th><th>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>640,8</td><td>–</td><td>552,6</td><td>88,2</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>328,345</td><td>239,482</td><td>47,923</td><td>40,94</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>735,358</td><td>434,76</td><td>288,598</td><td>12,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>333,129</td><td>55,9</td><td>248,353</td><td>28,876</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>452,19</td><td>13,483</td><td>374,391</td><td>64,316</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>891,023</td><td>15,0</td><td>535,923</td><td>340,1</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>885,707</td><td>185,0</td><td>652,203</td><td>48,504</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1241,86</td><td>433,593</td><td>712,088</td><td>96,179</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 031,525</td><td>–</td><td>356,93</td><td>674,595</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>356,93</td><td>–</td><td>356,93</td><td>–</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>356,93</td><td>–</td><td>356,93</td><td>–</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>356,93</td><td>–</td><td>356,93</td><td>–</td></tr>
</table>
<br>Чараларны һәм объектларны финанслау күләмнәре төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә тәгаенләштерелергә тиеш»;</td></tr>
</table>

«Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 2025 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелергә тиеш:<br>пассажирларга хезмәт күрсәтелде – 5,7 млн.кеше;<br>йөкләр ташылды – 8 960,1 тонна»; |

3 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга автомобиль, шәһәр электр транспортын, шул исәптән метроны үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2025 елларга автомобиль, шәһәр электр транспортын, шул исәптән метроны үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа)»; |

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс ресурслары – 36 398,066 млн.сум, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 160 млн.сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 34 881,066 млн.сум;<br>бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча – 1 357,0 млн.сум (шул исәптән инвесторлар акчасы).<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә: |

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 2 707,515 | – | 2 707,515 | – |
| 2015 | 3 454,149 | 160,0 | 3 244,149 | 50,0 |
| 2016 | 3 185,514 | – | 3 175,514 | 10,0 |
| 2017 | 1 101,002 | – | 1 101,002 | – |
| 2018 | 1 122,451 | – | 1 122,451 | – |
| 2019 | 1 735,468 | – | 1 735,468 | – |
| 2020 | 3 830,801 | – | 3 830,801 | – |
| 2021 | 8 008,022 | – | 8 008,022 | – |
| 2022 | 3 138,277 | – | 2 541,277 | 597,0 |
| 2023 | 2 821,615 | – | 2 471,615 | 350,0 |
| 2024 | 2 821,626 | – | 2 471,626 | 350,0 |
| 2025 | 2 471,626 | – | 2 471,626 | – |

| | |
|---|---|
| | Чараларны һәм объектларны финанслау күләмнәре төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә тәгаенләштерелергә тиеш»; |

«Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлының беренче абзацында «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

4 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында логистика үзәкләре челтәрләрен үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс ресурслары – 2 790,325 млн.сум, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 513,47 млн.сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 976,855 млн.сум;<br>бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча – 1 300,0 млн.сум.<br>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә: |

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 1 197,517 | 220,662 | 976,855 | – |
| 2015 | 292,808 | 292,808 | – | – |
| 2016 | – | – | – | – |
| 2017 | – | – | – | – |
| 2018 | – | – | – | – |
| 2019 | – | – | – | – |
| 2020 | – | – | – | – |
| 2021 | – | – | – | – |
| 2022 | 300,0 | – | – | 300,0 |

<table>
<tr><td></td><td>
<table>
<tr><td>2023</td><td>500,0</td><td>–</td><td>–</td><td>500,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>500,0</td><td>–</td><td>–</td><td>500,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td></tr>
</table>
Чараларны һәм объектларны финанслау күләмнәре төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны эшләгәндә тәгаенләштерелергә тиеш»;</td></tr>
</table>

«Ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлының беренче абзацында «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

5 нче ярдәмче программа паспортыннан соң беренче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 22 ноябрендәге б-1734 номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең транспорт стратегиясе» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 ноябрендәге б-3363 номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең транспорт стратегиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче ярдәмче программа паспортыннан соң икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Стратегиядә 2035 елга Россия Федерациясенең һәр регионы өчен, шул исәптән Татарстан Республикасы өчен дә, транспорт логистикасының ориентирлары һәм бурычлары куелды.»;

«2014 – 2024 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклап калу» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа исемендә «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2025 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклап калу» (алга таба – Ярдәмче программа)»; |

«Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен кирәкле финанс ресурслары 575 904,572 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган:<br>федераль бюджет акчасы – 189 017,651 млн.сум;<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 376 509,567 млн.сум, шул исәптән 58 398,25 млн.сумы (2016 елда – 7 388,04 млн.сумы, 2017 елда – 22 010,21 млн.сумы, 2018 елда – 20 000,0 млн.сумы, 2019 елда – 9 000,0 млн.сумы, 2020 елда – 9 000,0 млн.сумы) |

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасының социаль тармакларын һәм иҗтимагый инфраструктурасын үстерү концепциясен тормышка ашыру кысаларында юл хуҗалыгы инфраструктурасын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау чараларына;
муниципаль юл фондлары акчасы – 9 053,7 млн.сум;
бюджеттан тыш чыганаклардан (Моношәһәрләрне үстерү федераль фонды) – 1 323,654 млн. сум.
Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга җәлеп итүгә планлаштырыла торган бюджет ассигнованиеләре күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

(млн.сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән түбәндәгеләр акчасы | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган федераль бюджет | Татарстан Респуб-ликасы бюджеты | җәлеп итәргә план-лашты-рыла торган муни-ципаль юл фонд-лары | җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган бюджеттан тыш чыганак-лардан (Моношә-һәрләрне үстерү федераль фондыннан) |
| 2014 | 33 171,367 | 10 426,591 | 21 911,176 | 833,6 | – |
| 2015 | 33 737,494 | 8 976,922 | 23 671,372 | 680,7 | 408,5 |
| 2016 | 38 789,566 | 11 106,118 | 26 567,034 | 785,1 | 331,314 |
| 2017 | 47 883,903 | 11 200,508 | 35 412,26 | 1 079,7 | 191,435 |
| 2018 | 55 843,726 | 10 475,423 | 44 141,082 | 1 028,7 | 198,521 |
| 2019 | 53 976,969 | 14 789,626 | 37 942,238 | 1 087,6 | 157,505 |
| 2020 | 56 879,971 | 16 310,91 | 39 434,232 | 1 122,4 | 12,429 |
